**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«01» ноябрь 2019 ел** **№ 312**

2020 елга «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 05.07.2010 ел № 545 карарының 3 пункты нигезендә, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Азнакай муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында» 25.03.2011 ел № 65 карарын исәпкә алып, карар чыгара:

1. 2020 елга «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын, №1 кушымта нигезендә, расларга.

2. «Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениясенә әлеге карарның 1 пунктында расланган гомуми белем бирү учреждениеләрен балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р.Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына 1 нче кушымта
«____» ________ 2019 № ______

2020 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | елга бер автотранспорт чарасына ставка, сум | елына автотранспорт чарасының бер километр узу ставкасы, сум |
| КАВЗ | 114254 | 36,60 |
| ПАЗ | 114511 | 36,54 |
| ГАЗ «Газель» | 108623 | 29,95 |
| УАЗ | 108170 | 28,64 |
| FIAT | 107912 | 27,25 |
| Peugeot Boxer | 108427 | 26,89 |
| Ford Transit | 109251 | 29,98 |